***Мәктәп туры***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2021-2022 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 38**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Калын сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) [ы];**
   ә) [э];
   б) [ә];
   в) [и].

2. Саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [в];
   ә) [д];
   б) [з];
   **в) [һ].**

3. Антонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *җылы – кайнар*;
   **ә) *карт – яшь*;**
   б) *шәһәр – кала*;
   в) *председатель – рәис*.

4. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *илле;*
   **ә) *ундүрт*;**
   б) *егерме өч*;
   в) *туксан*.

5. Төшем килешенең кушымчаларын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *-ның/-нең;*
   ә) *-га/-гә, -ка/-кә*;
   **б) *-ны/-не*;**
   в) *-да/-дә, -та/-тә*.

6. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *яшел;*
   **ә) *яшелрәк;***
   б) *ямь-яшел;*

в) *яшькелт.*

7. Күрсәтү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) *син;*
ә) *кем;*
б) *аларныкы;*
**в) *теге.***

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Илгизнең энесе балалар бакчасына йөри.*

**а) хикәя;**
ә) сорау;
б) боеру;
в) тойгылы.

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(6 балл)**

*[с] – **саңгырау** тартык аваз. [у] – **калын** сузык аваз. Калын – юан – **синонимнар**. Алтынчы, сигезенче – **тәртип** саннары. Укысын – **боерык** фигыль. Ия һәм хәбәр – җөмләнең **баш** кисәкләре.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*Как красив осенний лес! Березки надели золотые платья. Сосны и ели остались зелёными. Пестрый ковёр листьев шуршит под ногами. А сколько грибов в лесу!*

2. Көзге урман турында дәвам итеп, 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**